РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

16.07.2024 Олы Кайбыч ав. № 273

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының коррупциячел хокук бозуларны кылган өчен муниципаль хезмәткәрләренең җаваплылыгы турында» 2013 елның 28 гыйнварындагы 153 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 10 июлендәге 286-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Кайбыч муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының коррупциячел хокук бозулар кылган өчен муниципаль хезмәткәрләренең җаваплылыгы турында» 2013 елның 28 гыйнварындагы 153 номерлы Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

кушымтада 2.4 пунктның 2 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«яллаучының вәкиле булган муниципаль хезмәткәрнең үзенә буйсынган муниципаль хезмәткәрнең мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынуы барлыкка килү турында билгеле булган муниципаль хезмәткәрләргә, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яисә җайга салу буенча чаралар күрмәү;».

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http:/kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталы»нда бастырып чыгарырга.

Совет Рәисе,
Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы Башлыгы А.И.Рәхмәтуллин